**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлегенең Иске-Мунча торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**29.11.2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Иске-Мунча торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлегенең Иске-Мунча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә Сез ризамы?,1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, армиядә хезмәт итүчеләрдән, СВОда катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

*Иске-Мунча торак пунктындагы христиан зираты территориясен койма белән әйләндереп алуны ремонтлау (евр677штакетник сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)*

3.Әлеге карарны Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге башлыгы ______________ Х.Х.Нәбиуллин